КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 апрель г.Казань № 367

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Белем бирү өлкәсендә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру сыйфатын чагылдыручы индикаторлар составын һәм әһәмиятен раслау турында» 2006 ел, 17 май, 252 нче;

«Балигъ булмаганнар эшләре һәм алар хокукларын яклау комиссияләре эшчәнлеген оештыру һәм белем бирү буенча бирелгән дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның сыйфатын чагылдыручы индикаторлар әһәмияте һәм составы турында» 2006 ел, 3 июль, 332 нче;

«Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның сыйфатын чагылдыручы индикаторлар составын һәм әһәмиятен раслау турында» 2006 ел, 3 июль, 334 нче;

«Административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру сыйфатын күрсәтүче индикаторлар составы һәм мәгънәләре турында» 2006 ел, 28 июль, 381 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин